РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КОРСАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422051, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Корсабаш, ул. Школьная, 28
тел. (84362) 2-27-49

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КУРСАБАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

422051, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Курсабаш авылы, Школьная урамы, 28 йорт
тел. (84362) 2-27-49

e-mail: korsab.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
01.07.2021

КАРАР
№27

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Курсабаш авыл башкарма комитеты
тарафыннан 2021 елның 15 июнендә 26 номерлы
карары белән расланган Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы Курсабаш авыл башкарма
комитеты тарафыннан социаль наем шартнамәләре
һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннары
наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннарын
яллаучылар өчен торак урыннардан (наемга алу өчен
түләү күләмен исәпләү тәртибе турындагы)
нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакындагы

Россия Төзелеш Министрлыгының «Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының 2016 елның 27 сентябрендәге 668/пр номерлы боерыгы белән расланган социаль наем шартнамәләре һәм дәүләт яки муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннарын яллаучылар өчен торак урыныннан файдалану өчен түләү күләмен билгеләүнең методик күрсәтмәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 19 июнендәге 892/пр номерлы боерыгы кабул ителүгә бәйле Россия Федерациясе Торак кодексына таянып, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл башкарма комитетының 2021 елның 15 июнендәге 26 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге муниципаль торак фондының социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондыннан торак урыннарны наемга алу шартнамәләре буенча торак урыннары наемга алучылар өчен торак урыннардан (наемга) файдалану өчен түләү күләмен исәпләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.2. Яллаучылар өчен түләү коэффициенты торак урыныннан файдаланган өчен түләү (наем өчен түләү) билгеләнгән вакытка – 0,3 күләмендә билгеләнә.

Шул ук вакытта гражданнарның түбәндәге категорияләре өчен түләүнең ташламалы критерийлары билгеләнә:
- 3 һәм аннан да күбрәк баладан торган күп балалы гаиләләр өчен-0,15;
- пенсионерлар (55 яшькә җиткән хатын-кызлар һәм 60 яшькә җиткән ир-атлар өчен-0,15;
- инвалидлар өчен-0,15.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълуматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2021 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Авыл җирлеге башлыгы А.Р. Гыймадиев